| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>УРНЯКСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,<br>Арский муниципальный район, 422019 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ҮРНӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ<br>Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,<br>Арча муниципаль районы, 422019 |

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru


**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**25 октябрь 2021 ел** **№10**

**Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Гарталовка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Үрнәк авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Гарталовка авылында Гарталовка авылы, Урман урамы, 5 нче йорт яны адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 16 ноябренә 11 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәгемәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Гарталовка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 327,5 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 655 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тубәндәге эшләргә юнәлдеру белән килешәсезме:

1. Юл-урам челтәренә вак грунтташ урнаштыру:
Лесная ур., 9 нчы йорттан башлап;
2.Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту
3.МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алуны өлешчә финанслау (Ротор чапкычы, фронталь төягеч)2. Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Гарталовка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Гарталовка авылы, Урман урамы, 5 нче йорт.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков